Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

22 ноябрь 2019 ел № 5

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыенының беренче, икенче этаплары тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре) турында» 2019 елның 22 ноябрендәге беркетмәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында 2019 елның 22 ноябрендә узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дерес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Ямаш авылы, Совет урамы, 109А нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга (халыкка җиткерергә) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Ямаш авыл җирлеге башлыгы А.И. Чуркин